ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Джалиля, д.23/33, г. Мамадыш,
Республика Татарстан, 422190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
М.Җәлил ур, 23/33 й., Мамадыш ш.,
Татарстан Республикасы, 422190

Тел.: (85563) 3-15-00, 3-31-00, факс 3-22-21, e-mail: mamadysh.ikrayona@tatar.ru, www.mamadysh.tatarstan.ru

**Постановление** **Карар**

№ 416 от «31» 10 2025 г.

Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 07 октябрендәге «Мамадыш муниципаль районы хезмәткәрләренең гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау, су объектларында янгын куркынычсызлыгын һәм кешеләрнең иминлеген тәэмин итү өлкәсендә хезмәт хакы шартлары турындагы нигезләмәне раслау хакында» 1187 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2025 елның 26 сентябрендәге «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 елның 14 августындагы 569 номерлы карары белән расланган Гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләрнең иминлеген тәэмин итү өлкәсендә муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләренең хезмәтенә түләүгә Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары бюджетлары чыгымнары күләмен билгеләү методикасына үзгәрешләр кертү турында " 780 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 07 октябрендәге «Мамадыш муниципаль районы хезмәткәрләренең гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау, су объектларында янгын куркынычсызлыгын һәм кешеләрнең иминлеген тәэмин итү өлкәсендә хезмәт хакы шартлары турындагы нигезләмәне раслау хакында» 1187 номерлы (Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 7 декабрендәге 422 номерлы, 2024 елның 30 маендагы 202 номерлы, 2024 елның 12 сентябрендәге 780 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләрнең иминлеген тәэмин итү өлкәсендә муниципаль берәмлек хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турындагы Нигезләмәнең II бүлегендә

0000012982

«хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары " ның 1 нче таблицасын яңа редакциядә түбәндәгечә бәян итәргә:

«1 нче Таблица

| № п/п | Хезмәткәрләр вазыйфасы | Вазифаи окладның размеры, сум |
|---|---|---|
| 1 | Учреждение җитәкчесе | 33 345,00 |
| 2 | Оператив кизү торучы | 25 650.00 |

2. Әлеге карар 2026 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://mamadysh.tatarstan.ru// адресы буенча һәм Мамадыш муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче вазифаларын
башкаручы Р.М.Никифоров